ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10. 12. 2025 г.Мензелинск № 414

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 31.05.2019 ел № 559 «Минзәлә муниципаль районы җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе булган муниципаль учреждение булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия һәм үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү максатларында Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. «Минзәлә муниципаль районы җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе булган муниципаль учреждение булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия һәм үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 31.05.2019 ел № 559 карарына (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 01.12.2020 ел № 1158, 23.12.2022 ел № 432, 19.06.2024 ел № 192, 21.10.2024 ел № 324, 30.04.2025 ел №145) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган муниципаль учреждение булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия һәм Минзәлә муниципаль районы җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе булган үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең 3 пунктында түбәндәге редакциядә таблицаны бәян итәргә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сумнарда |
|---|---|
| | Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен һәм Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органы) структур бүлекчәсе (бүлеге)булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |

| | |
|---|---|
| Җитәкче | 38 100 |
| Җитәкче урынбасары | 35 000 |
| Бүлек башлыгы | 33 600 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 30 600 |
| Әйдәп баручы бухгалтер (программист) | 30 600 |
| Бухгалтер | 29 000 |

2. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны 2026 елга Минзәлә муниципаль районы бюджетында каралган акчалар чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 01 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ рәисе Кондратьева Ландыш Илдусовнага йөкләргә.

Җитәкче Кәримов М.Р.

Исполнительный комитет Мензелинского муниципального района